| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от__19.06.2023___** г. Казань **№ __462/2023__**

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 22 февралендәге Пр-20/2023 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 22 февралендәге Пр-20/2023 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

3.9.2 пунктта:

икенче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләре белән алыштырырга, «дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев